СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.54, с. Верхний Услон,
422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЮГАРЫ ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Чехов ур., 54 нче йорт, Югары Ослан авылы,
422570

РЕШЕНИЕ | КАРАР

30.10.2020 ___ с. Верхний Услон № 2-21_____

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Советының «Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018нче елның 24нче апрелендә кабул ителгән 38-184нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020нче елның 6нчы августындагы 658нче номерлы карары, Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан авыл җирлеге Советының 2018нче елның 24нче апрелендә кабул ителгән 38-184нче номерлы «Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Советының
2018нче елның 24нче апрелендәге
38-184нче карарына

1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 18742 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 18397 |

1.2. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге   Советының
2018нче елның 24нче апрелендәге
38-184нче  карарына
2 нче кушымта

Югары Ослан авыл җирлеге Башлыгының акчалата бүләкләре күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы урынбасары | 13968 |

2. Әлеге карар 2020нче елның 1нче октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә.

Совет Рәисе
Югары Ослан  муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге
Башлыгы                                                  М. Г. Зиатдинов